ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.04.2021 г.Лениногорск № 423

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 6 августындагы 309 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районы территориясе чикләрендә территориаль җәмәгатьчелек үзидарәләренә ярдәм итү өчен Лениногорск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үткәрүгә, территориаль иҗтимагый үзидарәләр җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә, башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 31 октябрендәге 988 номерлы карарына таянып, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 6 августындагы 309 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районы территориясе чикләрендә территориаль җәмәгатьчелек үзидарәләренә ярдәм итү өчен Лениногорск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 пунктны түбәндәге эчтәлекле 2 абзац белән тулыландырырга:

«Субсидияләр «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Лениногорск муниципаль районы составына керүче Лениногорск

шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына, килешү нигезендә территориаль иҗтимагый үзидарәләргә ярдәм итүгә бирелә»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Субсидияләр Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) тарафыннан Лениногорск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү турындагы килешү (алга таба - Килешү) нигезендә бирелә, ул Башкарма комитет һәм субсидияләр алучы арасында төзелә (әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә) анда түбәндәге нигезләмәләр каралган:

5 пунктның «а» пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) субсидияләр күләме, максатлары, бирү һәм алардан файдалану сроклары;»;

«а» пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) субсидияләрдән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченә ирешмәүнең мәгънәсе һәм нәтиҗәләре;»;

түбәндәге эчтәлектәге «ж» пункты белән тулыландырырга:

«ж) Килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы».

2.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Җитәкче З.Г.Михайлова

И.Р.Хәйбрахманов
5-44-72